ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ БОЛГАЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

2023 ел, 3 июль №96

Олы Болгаер авыл җирлегенең муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2023 елның 13 июнендәге N258-ФЗ номерлы “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 гыйнварындагы 82 номерлы “Олы Болгаер авыл җирлегенең муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында” карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1 нче номерлы кушымтада

18.3 пунктның 1 пунктчасын 2 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе яки “Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге N 273-ФЗ Федераль законның 13.4 статьясына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлеге тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре нигезендә;”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

3.Бу карарның үтәлешен контрольләүне җирлек башлыгына йөкләргә.

Олы Болгаер авыл җирлеге башлыгы-
Олы Болгаер авыл җирлеге Советы Рәисе З.И.Сәйфуллина